**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 августындагы 3367 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 8 ноябрендәге 2346 номерлы «Казан шәһәре территориясендә торак урыннарны гражданнар милкенә тапшырганда (хосусыйлаштырганда) документларны тутыру тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Казан шәһәре Думасының 2024 елның 26 июнендәге 18-30 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 24-3 номерлы «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 8 ноябрендәге 2346 номерлы «Казан шәһәре территориясендә торак урыннарны гражданнар милкенә тапшырганда (хосусыйлаштырганда) документларны тутыру тәртибе турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2007 елның 4 октябрендәге 3232 номерлы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 30 июнендәге 5260 номерлы, 2019 елның 24 гыйнварындагы 240 номерлы, 2020 елның 11 февралендәге 418 номерлы, 2022 елның 19 августындагы 2794 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 һәм 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесен (Л.Р.Шәрипова) (алга таба – Идарә) торак урыннарны хосусыйлаштыруга документлар рәсмиләштерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә вәкаләтләргә.

4. Идарәгә:

4.1. «Торакны хосусыйлаштыру» программа продуктына тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

4.2. Казан шәһәре территориясендә яшәүче гражданнарга Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча

идарәсендә (алга таба – ТР буенча Росреестр идарәсе) аларның мәнфәгатьләрен кайгыртуда ярдәм күрсәтергә.

4.3. Казан шәһәре муниципаль милкендәге торак урыннарны хосусыйлаштыру мәсьәләләрендә, шул исәптән хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү өлешендә, гражданнарны билгеле бер чор аралыгында теркәү турында белешмәләр булмаган очракларда гражданнарга ярдәм күрсәтергә».

1.2. 6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. “Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесенә (Р.З.Кәримов) торакны хосусыйлаштыру буенча архив документларын билгеләнгән тәртиптә Идарәгә тапшырырга».

1.3. кушымтада:

1.3.1. 1.3 пунктта «“Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесе» сүзен «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

1.3.2. 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.5. Әлеге Инструкциядә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын һәм норматив актларын үтәп, Казан шәһәре территориясендә торак урыннарны гражданнар милкенә тапшыру процессын оештырган, торакны хосусыйлаштыру буенча бердәм сәясәтне үткәрүдә хокукый ярдәм күрсәтүне тәэмин иткән өчен җаваплылык үзәге итеп Идарә билгеләнә.»;

1.3.3. 1.6 пунктында «торак урыннарны хосусыйлаштыруга документлар рәсмиләштерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә вәкаләтле муниципаль оешма» сүзләрен «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

1.3.4. 2.1, 2.2 пунктларында «“Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесе» сүзен тиешле килештә «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

1.3.5. 2.7 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.7. Документларны кабул итү өчен җаваплы Идарә белгече гаризаны тутыруның дөреслеген тикшерә, гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тапшырылган документларның эчтәлеге белән чагыштыра, гаризаны электрон документ әйләнеше һәм Идарәнең эш башкару системасында эш башкару кагыйдәләре нигезендә терки һәм гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гариза керүе турында хәбәрнамә җибәрә, анда гаризаның керү теркәү номеры, гаризаны алу датасы, тапшырылган документлар файллары атамалары исемлеге (гариза электрон рәвештә кергәндә) я гаризага кушымта итеп бирелгән документлар исемлеге (документларны кәгазьдә алганда), муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелә»;

1.3.6. 2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.8. Билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән гаризага Идарә белгече кул куя»;

1.3.7. 2.9 пунктында «“Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесе» сүзен «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

1.3.8. 2.10 пунктын гамәлдән чыгарырга;

1.3.9. 2.11 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.11. Идарә белгече гаризаны теркәгәннән соң килә торган 14 эш көне эчендә торак урынны гражданнар милкенә тапшыруга шартнамә проектын (алга таба – хосусыйлаштыру шартнамәсе) теркәү номеры белән ике нөсхәдә рәсмиләштерә »;

1.3.10. 2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.13. Идарә белгече гариза бирүчегә, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең торак урынына элек теркәлгән милек хокукы шарты белән, хосусыйлаштыру шартнамәсе проектын ике нөсхәдә имзалау өчен тапшыра.

Идарә белгече гражданнар тарафыннан хосусыйлаштыру шартнамәсенә кул куелгач, хосусыйлаштыру шартнамәсенең бер нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра. Хосусыйлаштыру шартнамәсенең икенче нөсхәсе һәм тапшырылган документларның төп нөсхәләре, техник паспорттан һәм социаль наем шартнамәсеннән тыш, Идарәдә саклана.

Техник паспортның һәм социаль наем шартнамәсенең оригиналы мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

Шартнамәгә кул куелгач, мөрәҗәгать итүче идарәгә хосусыйлаштыру шартнамәсе нигезендә милек хокукы күчүен дәүләт теркәвенә алуга гариза белән мөрәҗәгать итә.

Идарә белгече хосусыйлаштыру шартнамәсен электрон элемтә ярдәмендә хосусыйлаштыру шартнамәсе нигезендә торак урынга милек хокукының күчүен дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенә җибәрә.

Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе хосусыйлаштыру шартнамәсе нигезендә торак урынга милекчелек хокукының күчүен дәүләт теркәвенә ала һәм күчемсез мөлкәт объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан хокук күчүен дәүләт теркәвенә алуны раслый торган өземтәне Идарә белгеченең электрон почтасына җибәрә.

Идарә белгече гражданинга гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, электрон почта, почта аша) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирә, бу турыда Гаризалар кабул итүнең һәм документлар бирүнең исәпкә алу кенәгәсенә тиешле язу ясала. Идарә белгече тарафыннан Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә нигезендә «Торакны

хосусыйлаштыру» программа продуктына тиешле үзгәрешләр кертелә. Теркәлгән хокуклар турында белешмәләр шулай ук “Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык комитеты” муниципаль казна учреждениесенә җибәрелә»;

1.3.11. 2.14, 2.15 пунктларын гамәлдән чыгарырга;

1.3.12. 2.17 пунктында «торакны муниципаль милеккә тапшыру шартнамәсе һәм » сүзләрен алырга;

1.3.13. 2.18, 2.19 пунктларында «“Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесе» сүзен «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

1.3.14. Казан шәһәре территориясендә торак урыннарны гражданнар милкенә тапшырганда (хосусыйлаштырганда) документларны рәсмиләштерү тәртибе турындагы Инструкциянең 1 номерлы кушымтасын түбәндәге редакциядә бирергә:

1.3.14.1. «________________________ районы хакимияте башлыгына» сүзләрен «Торак сәясәте идарәсе башлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.14.2. искәрмәләрнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Гариза кабул ителгән “___” _____________ 20__ ел.»;

1.3.14.3. искәрмәләрнең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«____________________________________________ __________ _____________________

(гариза кабул иткән белгеч вазифасы) (имза) (фамилия, инициаллар)»

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**